| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2020 Казан ш. № 394-10/э-2020

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен 2021-2025 елларга электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә аерым тарифлар билгеләү турында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы өчен, шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2021-2025 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары билгеләргә.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалының 2021-2025 еллар кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2020 № 394-10/э-2020
карарына 1 нче кушымта

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә 2021 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы | 2021 | 584 905,69 | 39,82 | 1,90030 | 584 905,69 | 39,82 | 1,90030 |
| | | 2022 | 603 867,54 | 39,82 | 1,96061 | 603 867,54 | 39,82 | 1,96061 |
| | | 2023 | 610 475,77 | 39,82 | 1,98163 | 610 475,77 | 39,82 | 1,98163 |
| | | 2024 | 585 418,23 | 39,82 | 1,90193 | 585 418,23 | 39,82 | 1,90193 |
| | | 2025 | 592 409,99 | 39,82 | 1,92417 | 592 409,99 | 39,82 | 1,92417 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2020 № 394-10/э-2020
карарына 2 нче кушымта

Үзенә карата электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген озак сроклы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы өчен 2021-2025 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Контрольгә тиешле чыгымнарның база дәрәҗәсе | Контрольгә тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Активлар саны буенча контрольгә тиешле чыгымнарның сыгылмалылык коэффициенты | Электр энергиясен технологик тоту (югалту) зурлыгы (электр челтәрләре буенча тапшырганда югалган электр энергиясе дәрәҗәсе), % | | | | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача дәвамлылыгы күрсәткече (Пsaidi) | Сатыла торган товарларның (хезмәтләрнең) сыйфат дәрәҗәсе | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача ешлыгы күрсәткече (Пsaifi) | Гамәлгә ашырыла торган технологик ялгауның сыйфат дәрәҗәсе күрсәткече (Птпр) |
| | | | млн сум | % | % | ВН | СН-I | СН-II | НН | сәгать | данә | |
| 1 | «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы | 2021 | 18 485,10 | 1 | 75 | 0,06 | 0,00 | 2,53 | 0,00 | 0,258 | 0,165 | 1 |
| | | 2022 | x | 1 | 75 | 0,06 | 0,00 | 2,53 | 0,00 | 0,254 | 0,162 | 1 |
| | | 2023 | x | 1 | 75 | 0,06 | 0,00 | 2,53 | 0,00 | 0,250 | 0,160 | 1 |
| | | 2024 | x | 1 | 75 | 0,06 | 0,00 | 2,53 | 0,00 | 0,246 | 0,157 | 1 |
| | | 2025 | x | 1 | 75 | 0,06 | 0,00 | 2,53 | 0,00 | 0,243 | 0,155 | 1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2020 № 394-10/э-2020
карарына 3 нче кушымта

«Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2021-2025 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Газпром энерго» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Урал яны филиалы | 2021 | 48 149,44 |
| | | 2022 | 49 710,38 |
| | | 2023 | 50 254,37 |
| | | 2024 | 48 191,63 |
| | | 2025 | 48 767,19 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге